Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 нче елның 14 нче октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. Урта мәктәпне бетергәч, 1965-1961нче елларда Казан дәүләт унивеситетында укыган. 1961-1963 нче елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән. 1963-2007 нче елларда берөзлексез Мулла Иле мәктәбендә хезмәт иткән: авыл мөгаллиме буларак, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, немец теле, гарәп теле, дин тарихы предметларын укыткан. 1968-1970 нче елларда – завуч, 1971-2000 нче елларда мәктәп директоры булган. Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы белән бүләкләнгән. Республика матбугатында педагогик хезмәтләре, әдәби әсәрләре әледән-әле басылып тора. 2000 нче елда "Кичке шәфәкъ", 2010 нчы елда "Мулла Иле моңнары", 2014нче елда "Бәхет үзәне", 2017нче елда "Аксакал язмалары" исемле шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр китаплары дөнья күрде. Равил хәзрәт Сәйфетдин 2005 нче елдан алып Мулла Иле мәчете имам-хатыйбы вазифаларын башкарды. 2017 нче елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. 2018 нче елның 10 февралендә вафат.

## Мулла Иле сандугачы

*Ялган шөһрәт, даннар белән түгел,*
*Эшең белән калдыр эзеңне.*
*Эзләп тапсын кеше мәхәббәте*
*Тормыш эчләреннән үзеңне.*
*... Матур сүзең, ыспай гәүдәң түгел,*
*Данга күмәр сине хезмәтең.*
*Сандугачны тыңла, – күренми дә, –*
*Җыры белән ничек хөрмәтле.*

Равил Сәйфетдинов

"Ялган шөһрәт белән түгел" исемле шигырьдән алынган бу юллар әтием Равил Сәйфетдиновның үзенә бик туры килеп тора. Мулла Иле урта мәктәбендә ярты гасыр берөзлексез тырышып, күңел биреп хезмәт итте ул. Аннан соң гомеренең соңгы көненә кадәр Мулла Иленең имам-хатыйбы вазифаларын башкарды. Йомшак күңелле, барлык кешеләрне дә эчкерсез ярата белә торган һәм үзе дә халык тарафыннан бик тә үз ителүче үзенә генә бертөрле булган зыялы шәхес иде ул. Аның әтисе Гарәфетдин ике бертуганы Хәйретдин, Җамалетдин белән сугышта һәлак булганнар. Өч баласын җуйган Фатыйма ананың елый-елый ике күзе сукырайган. Ә әнисе Бибинур көн-төн колхозда эшләгән. Ләкин шундый шартларда да ул тәрбияле бала булып үскән.

Исәпсез-хисапсыз хуҗалык эшләренә кереп батса да, әти бертуктаусыз белемен баету белән мәшгуль булган. Авыл мәктәбен бетергәннән соң, 1956 нчы елда, җиде фәннән имтихан биреп, җидегә берле конкурста җиңеп, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән. Тәлгать Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Индус Таһиров, Фәрит Йосыпов, Хатыйп Миңнегулов, Нурмөхәммәт Хисамов, Рөстәм Кутуев кебек әдипләр белән бергә укый ул.

Җәй айларында алар Казахстанда чирәм җирләрдә эшләгәннәр. Тырыш хезмәте өчен әти биредә “Чирәм җирләрне үзләштергәне өчен” дигән медаль белән бүләкләнгән.

Университетны уңышлы тәмамлаганнан соң, әтине укытучы итеп Самара өлкәсендәге Гали авылы урта мәктәбенә җибәрәләр. Татар дөньясында шундый авыл да булуына ул гаҗәпләргә кала: тау астына җәелеп утырган галәмәт зур авыл, ике меңләп йорты, алты меңләп кешесе бар.

Иң хикмәтлесе: авылда өч мәчет гөрләп эшләп тора, өч манарадан көн саен азан әйтелә. Ә бит бу дин инде күптән тыелган, мәчетләр юк ителгән заманда, төштә түгел – өндә. Авыл халкы аны бик тә яратып өлгерә, чөнки ул университетта, гарәп телен һәм графикасын бик яхшы үзләштергәнгә, Коръәнне, аңлап, тәҗвид белән укый белә. Үзе җитәкче булып эшли торган сыйныф кызларын мәчет юарга тоткарлыксыз җибәреп бара. Бу авылда халык татар телендә Казанга караганда да матур сөйләшә. Әти бу авылда ике ел эшли. Мәктәптә, бөтен көчен куеп, татар, рус, немец (немец телен ул яхшы белә иде) телләрен укыта. Шушы телләр буенча бик күп методик әдәбият туплый. Шул телләрне үзе берөзлексез чагыштырып өйрәнә. Аның бу өйрәнүе гомер буена китә, хоббиена әйләнә. Ул Тукай, Такташ, Илдар Юзеевларны тәүлекләр буенча русча сөйли ала, Пушкин, Евтушенколарны яттан сөйләп кенә калмый, татарчага тәрҗемә итә, Гёте, Гейнеләрнең шигырьләрен дә яттан белә һәм немецчәдән татарчага тәрҗемә дә итә.

Нәкъ менә Гали авылында әти укучылар йөрәгенә юл табарга өйрәнә. Укытучыга бик күпне белергә кирәк, һәм шуның иң кирәклесен тиешле методик алымнар аркылы укучыга җиткерә алу – иң әһәмиятлесе.

Ул һәр дәрескә иҗат итү ялкыны белән керә, үзенең максатына ирешә, шуннан үзенә биниһая шатлык, ләззәт ала. Үзенең гомерлек юлын табып, шул юлдан бер дә тайпылмыйча бара ул.

1963 нче елдан башлап әтинең бөтен гомере Мулла Илендә уза. 1968 нче елда аны директор урынбасары итеп куялар, ә 1971 нче елның беренче гыйнварыннан 2000 нче елның беренче сентябренә кадәр директор итеп эшләтәләр. Мәктәп җитәкчесе булса да, әти гомергә укытучы булып калды. Үзенең һәрбер дәресенә, зур багаж, керсез иман белән кереп, иң катлаулы темаларны да укучылар рәхәтләндереп үзләштерә торган итеп оештырды.

Һәр дәрестә укучылар мавыгып эшләделәр. Әти кырыслыкны, җитдилекне ягымлы юмор белән бик оста аралаштыра белә иде. “Кысып укытырга кирәк, ләкин диктатор булып түгел, елмаеп укытырга кирәк, тик уенга җибәреп түгел,” – дип әйтергә ярата иде ул. Мине дә татар теле һәм әдәбиятыннан әти укытты. Дәрестә миңа бернинди дә ташлама ясалмады. Инде мин мәктәпне бетергәч тә, башка төрле уйламыйча, нәкъ менә татар теле филологиясенә барып кергәнмен икән, бу – әтинең йогынтысы, сүзсез тәэсире, чөнки ул үзе мине беркайчан да тел белән укытучы булырга үгетләмәде. Әти, директор булса да, әдәбият-тел түгәрәкләрендә укучылар белән “җенләнә” иде. Хәтта өйдә дә алар язган хикәя, шигырьләрне укып, шулар дөньясында яшәде. Шул аңа чиксез зур рәхәтлек бирә иде. Аның Рәмилә Майорова дигән

укучысының әсәрләрен Казанда китап итеп бастырып чыгардылар ("Өмет бар килер көннәремдә", 2000 нче ел, Казан).

Директорлыкны әти бик тә гадел башкарды. Укытучыларның барысы белән дә ул уртак тел табып эшләде. Мондый хәл, әлбәттә, бик сирәк була. Бөтен коллектив рәхәт иҗат итү атмосферасында яшәде. Казанда татар мәктәпләре калмаганга, 1970-1990 елларда республиканың бик күп семинарлары нәкъ менә Мулла Иле мәктәбендә үтте. Әти һәр семинарда ачык дәрес күрсәтә һәм доклад ясый иде. Мәгарифне үстерү институтына курсларга укырга килгәч, Мулла Иле мәктәбендә уздырылган бик күп семинарларны җитәкләүче татар теле һәм әдәбияты кафедрасы җитәкчессе Хәбибуллина Закирә Нуриевна миңа гел: "Мин Мулла Иле мәктәбендә уздырылган семинарларда катнашучы укытучыларыма: "Бу мәктәп директорын, нинди чемоданга салып, үзебез белән алып китәргә икән? – дия идем," – дип әйтә торган иде. Аның: "Әтиең шикелле матур дәресләр күрсәтә алучы башка татар теле укытучысы юк шул", – дигән сүзләре әле дә колакта тора. Әйе, әти директор булып эшләгән еллар мәктәпнең укучыларга бай булган, нәтиҗәле рәвештә гөрләп эшләгән еллары иде.

Мәктәптә әти бик зур хуҗалык эшләре башкарды. Дөресрәге, булдырып булмаганны да булдырды. Монда аның беркатлылыгы да, дәүләт эшен үз эшеннән өстен куюы да ачык күренде. 1974 нче елда, җәйгә чыккач, балта осталары яллап, ике катлы иске агач мәктәпне сүттереп атты, урманнан бүрәнәләр ташытып, искесен һәм яңасын бергә кушып, бер катлы зур мәктәп төзетте. Ләкин мәктәп беренче сентябрьгә өлгермәде. Әй кыен булды әтигә! Укытуны төрле өйләрдә оештырды. Көлүчеләр күп булды. Ләкин беренче гыйнварга яңа мәктәп өлгерде. Укучылар, укытучылар җылыга тиенделәр. Мәктәпкә су кергән, котельныйдан рәхәт җылы килә. Гомердә күрмәгәнне күрде укучылар. Кыюлар юләрлеге шулай була икән.

1986 нчы елда хәзерге типовой таш мәктәп бинасында укый башладык. Бу бинаны булдыру өчен дә әтигә бик күп чабарга туры килде. Һәр кабинетны заманча итеп җиһазлауга иреште, газ керттерде, мәктәп тирәсен гөлбакчага әйләндерде, теплица ясатып, кыш буе җәмәгатеннән (әнидән) – теплицаның җитәкчесе булган биология укытучысыннан – яшелчәләр, чәчәкләр үстерттерә иде. Әти барында, теплица гөрләп эшләгән елларда, ел әйләнәсендә укучыларның табыннары яшелчәләрдән өзелмәде.

Әтинең үзен-үзе аямыйча эшләве нәтиҗәсе буларак, Мулла Иле мәктәбе 1970-2000 нче елларда, күп кенә казанышларга лаек булды. Татар теле һәм әдәбияты кабинеты республика күләмендәге конкурста беренче урынны алды, видеомагнитофон белән бүләкләнде (ул вакытта авыл халкы видеомагнитофонның нәрсә икәнен дә белми иде әле, бөтен авыл, мәктәпкә җыелып, шушы хикмәтле тартма эченнән чыга торган киноларны карарга йөрде), мәктәп "Ел мәктәбе" исеменә лаек булды. Татар теленнән, әдәбиятыннан бик күп еллар район олимпиадаларында беренчелекне Мулла Иле укучылары яуладылар...

*Кичтем кырык елны бертоташтан,*
*Офыкларга зарыгып карадым.*

*Күндәм бурлак кебек җигелеп тарттым*
*Мәктәп дигән заман корабын.*

Равил Сәйфетдиновның хезмәтләре бәяләнмичә калмады. Аңа “Россиянең мәгариф отличнигы”, “Татарстанның атказанган укытучысы” исемнәре, СССР Мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты, “Хезмәт ветераны” медале бирелде.

Әтинең үз тәҗрибәсеннән алып язылган бик күп мәкаләләре “Мәгариф” журналында басылдылар. Ул гомер буе матбугат белән бергә яшәде. Өйгә дистәләгән газета, ким дигәндә биш-алты журнал яздыра иде. Безнең өйдә нинди генә китап юк. Әти гомере буена китап җененә сөренеп яшәде. Шәһәргә барган саен, портфеленә китап тутырып кайта иде. Аларның ул берсен дә югалтмыйча сакларга тырышты. Китап сорап, үзебез һәм күрше авыллардан әллә кемнәр килә торган иде. Сораган китапларын табып биргәч (картотека булмаса да, ул аларның һәрберсенең кайда торганын белә!), түбәсе күккә тия иде. Әти гел шундый нәрсәләрдән тәм табып яшәде, ул акча исәбен гомер буе белмәде. Ә менә бик кадерле берәр китабын югалтсалар (андый очраклар булгалады), иң зур нәрсәсен югалткандай, шактый эче пошып йөри иде. Мөгаен, безнең өй китапханәсендәге китапларның берсе дә укылмый калмагандыр. Чөнки әти бик күпне белә иде. Мин кечкенәдән әтигә нинди генә сорау бирсәң дә, шунда ук җавап бирә алуына шакката идем. Авылда яшәүче Рәхим абый (“Җил” кушаматлы) кроссвордлар чишәргә ярата иде. Белми торган сүзләре булганда, гел әтигә шалтырата торган иде ул. Рәхим абый телефоннан әтигә сүзнең мәгънәсен укый. Әти: “Биш хәрефлеме, җиде хәрефлеме” , – дип кенә сорый да шунда ук җавапларын әйтеп бирә торган иде. Бик эрудицияле, энциклопедик белемле кеше иде ул. Әти телләрне бик яхшы үзләштерә иде. Немец телен яхшы белә иде. Гарәп телен дә шактый гыны үзләштереп, Коръәнне укыганда, тәрҗемә итеп бара иде.

Әти – шигырьләренә үз вакытында Хәсән Туфан югары бәя биргән үзенчәлекле шагыйрь. Мәктәп елларыннан алып гомеренең азагына кадәр ул иҗат белән шөгыльләнде.

Узган гасырның 50 нче елларында – “Хрущев җепшеклеге” чорында ук шигърият яратучыларга Равил Сәйфетдинов иҗаты яхшы таныш була. Аның шигырьләре, хикәяләре, мәкаләләре көндәлек матбугатта һәрдаим бастырыла тора. 1965 нче елда Мулла Иленә очрашуга килгән Хәсән Туфан ”Совет әдәбияты” журналында басылган “Күл буенда” шигырен яттан укып күрсәтә һәм “образлы язылган шигырь” дигән бәясен дә бирә. Әтинең 1958 нче елда басылып чыккан “Далада туган хисләр” дигән шигырьләр циклы бар. Аңарга сүз башын бик тә җылы итеп үзе дә җәй буе Казахстанда командировкада булган шагыйрь Мәхмүт Хөсәен язган. Үзенең “Чирәм җирләр сулышы” исемле әдәби җыентыгының (1960) “Икмәк, мәхәббәт һәм романтика” (98-153 б.) хикәясендә ул Казахстан далаларында “чирәм җирләрне үзләштерү”дә катнашучы Равил Сәйфетдиновны Муса Җәлил исемендәге отрядта эшләгән шагыйрь-студент Сәйфи Чирәмле Рәхимов образында сурәтләгән.

Халык шагыйре Илдар Юзеев “Ак төнбоек күлләрдә” (1998) дигән шигырьләр циклының сүз башында аның турында үзе “мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхес”ләрнең берсе дип язган. Язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин үзенең биш томлы “Сайланма әсәрләр”ендәге “Шигырь мәҗнүне” (Шагыйрь – мулла-укытучы Равил Сәйфетдин) (2013, икенче том) исемле саллы мәкаләсендә “әлегәчә тиешле бәясен алмаган шагыйрь” Равил Сәйфетдинов иҗатына югары бәя бирә. (489-510 б.)

Әтинең шигырьләре дә, проза әсәрләре бик матур телдә язылган. Ул үзенең талантлы әдип икәнен бик яхшы белә иде. Роман яки повесть язу турында да хыялланды ул. Ләкин һаман да үзенең эше күплегеннән гаҗиз иде. Бик күп вакытын мәктәп эше алып торды аның.

*Инде хәзер ничек өлгерергә?*
*Эшләнмәгән эшләр тау-тау тора.*
*Кайгырмас та идең әле –*
*Гомерләр бит узып бара.*

Язылган әсәрләренә карата әти бик тә таләпчән булды. Аның әле бастырылмаган шигырьләре дә бар. Бастырып чыгарылган китапларына ул үзе иң әйбәт дип санаган әсәрләрен генә туплады. Һәрберсен яңадан карап чыкты. Әти бик тыйнак кеше булып калды. Үз вакытында олы шагыйрьләребез бәясен алган шагыйрь була торып та, үзенең шигырьләрен китап итеп бастырырга, Язучылар советына керергә ашкынып йөрмәде. Беренче китабы инде олы яшькә җиткәндә генә бастырылды. Исеме дә “Кичке шәфәкъ” дип атала.

Төп эшләреннән тыш әти гел хуҗалык һәм җәмәгать эшләрендә кайнап яшәде. Үз бәхетен, бар юанычын Мулла Иле үзәннәрендә таптты.

*Гомерлеккә яшәү көче биргән,*
*Илһам биргән җирем шул минем.*

Без җәй саен болында гаилә белән чыклы иртәләрдә печән чаптык, челләләрдә дистәләгән чүмәләләр өйдек.

*Биредә мин ничә җәемне*
*Кибәннәргә куйдым яшереп.*

Гомер буе хуҗалыкта сыер-сарык тоттык, тавык-каз асрадык, урманнан җиләк-җимеш җыйдык. Ләкин натураль хуҗалык белән шөгыльләнү әтинең иҗади һәм педагогик хезмәтенә ярдәм генә итте шикелле. Ул һәрчак хөр күңелле, тәне табигать шифасы белән тулы иде. “Зыялы булу өчен табигать кочагында ял итү генә җитми, ә хезмәт итү дә зарур”, – дип әйтә иде әти. Колхозлар яшәгән чорда, үзебезгә бүленеп бирелгән кишер, суган, чөгендер участокларын әти, (кешеләр әйткәнчә, директор башы белән) барлык кешеләр белән рәхәтләнеп эшкәртә иде. “Кеше белән бергә эшләүгә бернәрсә дә җитми, тигезлек җанны рәхәтләндерә“, – дип әйтә торган иде ул. Ә үзе барлык кешеләрдән дә күбрәк һәм тырышыбрак эшли иде. Безне дә ул бик кечкенәдән хезмәткә өйрәтте. 4 нче сыйныфны бетергән елда миңа чалгы ясап бирде. Ул елны без авылыбыздан шактый еракта урнашкан Хөррияттә

(Совет елларында рөхсәтсез печән чабып була торган урында) бик күп кыяк чаптык.

Әти зур иҗтимагый эшчәнлек алып барды. Бик күп еллар авыл һәм район Советы депутаты булып сайланды. Район Советы депутаты буларак, авылларга асфальт юл салдыруга үзеннән зур өлеш кертте. Комсомол секретаре, агитаторлар коллективы җитәкчесе, пропагандист, Иптәшләр суды рәисе, "Белем җәмгыяте" лекторы, нәфис сүз остасы, үзешчән артист... Кемдер гомере буе шуларның берсе булып кына яши бит! Боларның барысын да ул чын күңелдән бирелеп эшләде. Бер үк вакытта кечке мәктәп эшләрен алып барды. Оста лектор, оратор буларак, инде университетта укыган еллардан ук бик күп урыннарда чыгышлар ясады. Аның кебек сөйләм куәсе көчле булган кешеләрне мин аз беләм. Сөйләгән вакытта ниндидер стилистик яки фактик хаталар җибәргәнен бөтенләй хәтерләмим мин. Аның дәресләре, вәгазьләре, чыгышлары, докладлары, ул эшләгән документлар – бары да үзенеке һәм бары да бик камил.

*Гомрем булды бертоташтан сары агым,*
*Җиткән икән ничек кенә сабырларым.*

Әти авылыбыз һәм районыбыз тарихын өйрәнүдә зур хезмәт куйды. 1990 нчы елда авылның 750 еллык юбилее республика күләмендә нәкъ менә аның тырышлыгы нәтиҗәсендә зурлап билгеләп үтелде. Әти анда авыл тарихына багышланган зур доклад белән чыкты. Мәктәптә республика музейлары көнләшерлек "Авыл тарихы" музеен оештырды.

Руссия мөфтиләр шурасы берничә ел рәттән мәүлид ае уңае белән "Мөхәммәт Мостафа сәллаллаһу галәйһи вә сәллам – һәр ике дөньяга рәхмәт йөзеннән җибәрелгән Пәйгамбәребез" дигән темага карата татар һәм рус телләрендә иҗат ителгән иң яхшы шигъри әсәрләргә бәйгеләр үткәреп килде. Әти дә, соңгыларында катнашып, 2009 нчы елгысында "Иман нуры" дигән шигыре беренче урынга чыккан иде. 2011нче елда "Сәхабәләр килгән Болгарга" дигән шигыре кабат җиңүгә лаек булып, әти, Шураның рәисе мөфти шәйх Равил хәзрәт Гайнетдин чакыруы буенча, Мәскәүгә барды һәм 22 нче февральдә мәркәзебезнең Җәмигъ мәчетендә мәүлид аена багышлап үткәрелгән форумда – дин әһелләре һәм зыялылар җыенында катнашты. Мәчетнең конференц-залында Мөфти хәзрәт, әтине котлап, диплом һәм бүләкләр тапшырды, Татарстан халкына, шул җөмләдән Мулла Иле кешеләренә үзенең сәламнәрен юллады. Шигыре шактый озын булса да, аны әти трибунадан залдагыларга тулысынча укып чыкты, чөнки зур хөрмәт күрсәтеп, яратып тыңладылар. Миңа да әлеге шатлыклы вакыйганың шаһиты булу бәхете тиде.

*Ул Муллагол, авыл исеме булып,*
*Гасырларга калган балкырга.*
*Авылымның чишмә башы – Болгар,*
*Серләр тулы хикмәт бар монда.*

Гаҗәп игътибарлы һәм хәтерле кеше буларак, әти авылдагы һәм якын-тирәдәге хикәятләрне, мәзәк хәлләрне хәтерендә сеңдереп бара һәм аларны, әдәби яктан эшкәртеп, вакытлы матбугатта бастырып чыгара торган иде.

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай һәм “татар тарихы атасы” Шиһабетдин Мәрҗаниләрнең Мулла Илендә булулары, шушы авылда туып үскән Гайнан Вәисовның Ясная Полянада Лев Толстой янында кунакта булуы турындгы яңа эчтәлектәге материаллардан торган хикәяләре һәм мәкаләләре генә ни тора аның!

Әти гомере буе туган ягы, аның матур табигате, гүзәл кешеләре турында язды. Яшел Үзән шәһәренә багышланган шигырьләре, шул исәптән поэмасы да, гимны да бар аның. Кызганычка каршы, соңгысының әлегәчә көе юк. Яшел Үзәндә яшәгән Азат Вергазов, Мәхмүт Хәсәнов, Идрис Туктарлар турында бик матур истәлекләр язып калдырды ул.

Әти гаҗәп дәрәҗәдә тиз эшли иде. Газета-журналларга мәкаләләрне турыдан-туры акка берничә биттә бер хатасыз язып ата торган иде. Аңа характеристика сорап килүче элеккеге мәктәп укучыларына ул теләсә кайсы вакытта, тиз арада аларның бөтен якларын тулысынча тасвирлап, документ ясап бирә торган иде. Печән чапканда да, җиләк җыйганда да ул беренче иде. Чалгыны да бик шәп кайрый белә иде ул. Әти янда булганда, мин чалгымны аңа кайратырга тырыша идем.

*Кайрадым мин чалгы һәркемгә,*
*Кайрамадым тешне беркемгә.*

Әти киләчәккә һәрвакыт өмет белән карап яшәде. Теләсә кайсы вакытта үзен юата, килеп туган кыен хәлләрдән чыгу җаен таба белә иде.

*Болытлар артында – зәңгәр күк,*
*Болытлар артында – ай-кояш.*
*Кышын да шомырттай карлардан*
*Хуш исләр таратып аңкый яз.*

Әти гомеренең соңгы көненә кадәр тирән хәтер һәм төгәл акыл белән яшәде. Мөгаен, ул гомеренең һәрбер көнен бик яхшы хәтерләгәндер. Ул кайсы елның кайсы көнендә бәрәңге утыртылуны, кайчан печәнгә төшүләрне бик зур төгәллек белән табигать күренешләрен дә тасвирлап сөйли торган иде. Үзе укыткан укучыларның кайсы партада утыруларын да бик төгәл хәтерли иде. Аның янына кунакка кайта торган Самара өлкәсенең Гали авылы укучылары белән дә алар нинди генә хәлләрне искә төшермиләр иде. (Гали авылы белән әти гомеренең азагына кадәр элемтәдә яшәде)

Бала чагыннан ишетеп килгән мәгълүматларны бөртекләп җыеп, безнең нәсел шәҗәрәсен дә (XVII гасырга кадәр) төзеп калдырды ул. Соңгы китабы “Аксакал язмалары”н да ул, беркайда да карамыйча, бик тиз арада язып тәмамлады.

Әти безне йомшаклык белән, дөрес яшәү үрнәген күрсәтеп тәрбияләде. Аның беркайчан да безгә начар сүзләр әйткәне булмады. Сүз сүгенүләр турында бармый. Гомумән, мин аның сүгенгәнен ишеткәнем булмады. Кайчакларда гына “елки-палки” дип әйтеп куя торган иде. Кул күтәрү дигән әйберне әти, гомумән, белми иде. Ул хәтта өйдәге терлек-туарны сүз белән генә карады. Ә бер үк вакытта әти бик таләпчән булды. Безне теләсә кайсы вакытта, теләсә нинди эшкә алып чыга киткән вакытлары күп булды торган...

Әтинең бөтен гомере кешеләргә игелек эшләп үтте. Аның янына тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кемнәр генә килми торган иде. Ул үзенә күрә борынгы Римдагы плебейларның халык трибуны ролендәге кеше кебек иде. Һәм янына килгән һичбер кеше буш китмәде.

Әти ниндидер эшләре белән мактанып йөрмәде, беркайчан да үзен башкалардан өстен куймады.

*Сандугачны тыңла, – күренми дә, –*
*Җыры белән ничек хөрмәтле.*

Үзе әйткән шушы сүзләргә әти гомере буе тугры калды. Шагыйрь буларак та, кеше буларак та.

***Сәйфетдинов Рөстәм Равил улы,***
***Яшел Үзән шәһәренең 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры***